**ИСПОЛКОМ АПАСТОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422350, пгт. Апастово, улица Советская, д.2

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422350,Апас штп. , Совет урамы, 2 йорт

тел.: (84376) 2-13-52, факс: 2-19-27, e-mail: apast@tatar.ru, http://apastovo.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 16 - 18.01.2021

## Җир эшләрен башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә :

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитетының «архитектура һәм шәһәр төзелеше өлкәсендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2020 елның 1 сентябрендәге 317 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

җир эшләрен башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында (14 нче кушымта)

2.3 пунктны 4.1 пунктчасы белән тулыландырырга. киләсе эчтәлектәге:

«4.1.Ордер, авария хәлендәге эшләрдән тыш, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмаган очракта бирелә.»;

2.6 пунктнына түбәндәге эчтәлекле җиденче абзац өстәргә:

«Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар турында мәгълүматлар ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында алына.».

2.Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Апас муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны инфраструктура үсеше буенча җитәкче урынбасары А. М. Хәсәновка йөкләргә.

**Җитәкче** **А. А. Тугушев**